Үткән заманнарда кешеләр иртәгесе көндә һәм якын көннәрдә һава торышының нинди булачагын ничек белделәр икән?

# Халык сынамышлары



elenaranko.ucoz.ru

СЫНАМЫШ УЛ ХАЛЫКНЫҢ КҮПЬЕЛЛЫК КҮЗӘТҮЛӘРЕ НӘТИҖӘСЕНДӘ ТУГАН ГЫЙБӘРӘ ЯГЪНИ ӘЙТЕЛМӘ.

СЫНАМЫШНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ– КИЛӘЧӘКНЕ ХӘБӘР ИТҮ:



elenaranko.ucoz.ru

# сынамышлар

- ел фасыллары белән бәйле
- күк җисемнәренең ничек күренүе белән бәйле
- табигать күренешләре белән бәйле
- Үләннәр, куаклар, агачларның төрле билгеләре белән бәйле
- Кешенең физик халәтендәге төрле үзгәрешләр белән бәйле
- Хайваннарның, кошларның, бөҗәкләрнең үз-үзләрен тотышлары

elenaranko.ucoz.ru

# ТАБИГАТЬ КҮРЕНЕШЛӘРЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ СЫНАМЫШЛАР

- Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була.
- Томан төшсә, артыннан явым була.
- Кыш көнендә урман җилсез шауласа, буран була.
- Ябалак кар яуса, аннан соң һава җылы, юеш булыр.
- Иртән үләнгә чык төшсә, көн аяз булыр.
- Ай колакланса, суыкка.
- Кояш кызарып баеса, аяз булыр.
- Кояш болыт эчендә баеса, явым булыр.
- Иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.
- Яңгыр тамчысы су өстендә эре булып күбекләнеп торса, янә яңгыр булыр.



elenaranko.ucoz.ru

# Ел фасыллары













elenaranko.ucoz.ru

# Ел фасыллары белән бәйле сынамышлар:

- Унбишенче февральдә көн җылы булса, яз яхшы килә.
- Бер елгы кыш җылы булса- икенче елгы кыш салкын булыр

- Март берендә аяз – аяз булыр бөтен яз.
- Апрельнең алтысында аяз булса, җәй коры килер. Әгәр болытлы булса ашлык уңарга булыр

- Июль аенең бер яңгыры патша сараена тора.
- Август аенда аяз булса, көз пычрак килер.

- Симән көнне яңгыр яуса, көз пычрак килә.
- Кар беренче октябрьгәчә күренсә, чана юлы тиз булмас
- Сентябрь аяз – кыш салкын..



elenaranko.ucoz.ru

Кыш. Сынамыш якынча туры килде.
Яз. Сынамыш якынча туры килде.
Җәй. Сынамыш якынча туры килде.
Көз. Сынамыш якынча туры килде.




elenaranko.ucoz.ru

Географик  диктант «Һава торышы сынамышлары»

1 вариант “Аяз, кояшлы көнгә карата сынамышлар”, 2 вариант «Болытлы, явымлы көнгә карата  сынамышлар”

1. Төтен җиргә төшә.
2. Иртән аяз, көндез өем болытлар, кичен болытлар юкка чыга.
3. Кичен күп булып чык төшә.
4. Кичкә таба көн җылыта.
5. Кичкә таба җил тына.
6. Тавыклар һәм чыпчыклар тузанда коена.
7. Болытлар җилгә каршы йөзә.
8. Эт эчәгесе чәчәкләре ябыла.
9. Карлыгач бик түбәнтен оча.
10. Болытлар җил уңаена йөзә.
11. Төнбоек чәчәге ачылмый һәм су өстенә чыкмый.
12. Төтен югары күтәрелә.
13. Көнбатыштан катлам болытлар килә, кичкә таба болытлар куера.
14. Энә караклары бергә җыелышалар, болганып очалар, гадәттәгедән көчлерәк шаулыйлар.



elenaranko.ucoz.ru

1 вариант

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | + | + | | + | | | | | + | | + | | |

2 вариант

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| + | | | + | | + | + | + | + | | + | | + | + |



elenaranko.ucoz.ru

# НӘТИҖӘ:

Халык сынамышларының фәнни һәм практик яктан зур кыйммәткә ия булуларын бик күп күренекле галимнәр билгеләп үтте. Сынамышлар, бүген безнең өчен, халыкның рухи дөньясын аның табигатькә поэтик карашын яхшырак аңларга ярдәм итүләре һәм фольклор җәүһәрләре булулары белән кыйммәтлеләр.



elenaranko.ucoz.ru